Мәмәшир авыл җирлеге Советы

КАРАР

28.01.2020 ел № 4

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы Уставы нигезендә Мәмәшир авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы кушып бирелгән Нигезләмәне расларга.
2. «Мәмәшир авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 5 февралендәге 4 номерлы, «Мәмәшир авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 23 сентябрендәге 18 номерлы Мәмәшир авыл җирлеге Советы карарлары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы И.Г.Ахметзянов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702

Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2020 ел
4номерлы карарына кушымта

Гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын)
оештыру һәм уздыру тәртибе турында НИГЕЗЛӘМӘ

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Авыл җирлеге) нигезендә эшләнгән.

## Бүлек 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1 статья Төп төшенчәләр

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

гавами тыңлаулар – җирлек халкының Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актлар проектларын ачык фикер алышу юлы белән җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул итү процессында, шулай ук федераль законнарда, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашу хокукларын гамәлгә ашыру формасы;

инициатив төркем – гавами тыңлауларда катнашу хокукына ия Россия Федерациясе гражданы яисә гражданнары төркеме;

җәмәгатьчелек вәкиле – физик зат, шул исәптән гавами тыңлауларда катнашучы карала торган мәсьәлә буенча фикер алышуда катнашырга хокуклы юридик затлар, берләшмәләр вәкилләре. Җәмәгатьчелек вәкилләренә җирле үзидарә яки дәүләт хакимияте органнарын тәкъдим итүче яки түләү шартнамәсе нигезендә алар эшчәнлегендә катнашучы хезмәт вазыйфалары нигезендә гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итүче затлар керми;

гавами тыңлауларда катнашучылар – җирле үзидарә органнары һәм аларның вәкилләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, гавами тыңлаулар экспертлары, гавами тыңлауларны уздыру буенча оештыру комитеты әгъзалары;

чыгыш ясарга хокуклы гавами тыңлауларда катнашучылар – әлеге Нигезләмәнең 6 статьясында билгеләнгән срокларда оештыру комитетына гавами тыңлаулар мәсьәләләре буенча чыгыш ясау өчен үз заявкаларын тапшырган җирле үзидарә органнары һәм аларның вәкилләре, җәмәгатьчелек вәкилләре;

оештыру комитеты – җәмәгать тыңлауларын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру гамәлләрен тормышка ашыручы паритет (тигез хокуклылык) башлангычларда җирлек җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларыннан, җирлек Советы депутатларыннан, җәмәгатьчелек вәкилләреннән һәм инициативалы төркемнәрдән төзелгән коллегиаль орган;

иҗтимагый фикер алышулар – иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр, шулай ук җирле үзидарә органнары карарлары проектлары буенча җәмәгать контроле максатларында кулланыла торган ачык фикер алышу, мондый фикер алышуда мәнфәгатьләре тиешле карар белән кагылучы җирле үзидарә органнары һәм оешмаларының вәкаләтле затлары, гражданнар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре мәҗбүри катнаша.

гавами тыңлаулар эксперты – гавами тыңлаулар мәсьәләләре буенча махсус белемгә ия һәм бу статуска вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән зат. Эксперт гавами тыңлаулар мәсьәләләре буенча рекомендацияләрне һәм тәкъдимнәрне язмача тапшыра һәм фикер алышуларда аларны аргументацияләү өчен катнаша.

2 статья. Гавами тыңлауларны үткәрү максатлары

Гавами тыңлаулар түбәндәге максатларда үткәрелә:

җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча мәҗбүри рәвештә гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль хокукый актлар проектлары турында авыл халкы катнашында фикер алышу;

гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләләр буенча җәмәгатьчелек фикерен ачыклау һәм исәпкә алу.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен әзерләү, үткәрү һәм билгеләү экспертларның ачыклыгы, хәбәрдарлыгы, ихтыярлылыгы, бәйсезлеге принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 статья. Гавами тыңлауларга чыгарыла торган сораулар

1. Гавами тыңлаулар җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча үткәрелә. Гавами тыңлауларының нәтиҗәсе җирле үзидарә органнары өчен тәкъдим итү характерына ия.

2. Гавами тыңлауларга мәҗбүри рәвештә түбәндәгеләр чыгарыла:

1) Җирлек Уставы проекты (алга таба – Устав), шулай ук Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында җирлек Советы карары проекты, Уставка, Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл яңадан күрсәтү формасына үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш;

2) җирле бюджет проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) Җирлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты;

4) җирлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәләләр, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән йә җыеннарда белдерелгән җирлек халкының ризалыгын алу таләп ителә торган очраклардан тыш;

5) генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияләрне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турындагы карар проектлары, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читләштерүгә рөхсәт бирү турындагы карар проектлары буенча, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда, җир биләмәләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләләре буенча оештыру һәм үткәрү тәртибе авыл җирлеге Уставы һәм (яки) шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып, җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә торган иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар үткәрелә.

6) ачык сервитутлар билгеләү мәсьәләләре;

7) җылылык белән тәэмин итү схемасы проекты;

8) федераль законнарда билгеләнгән башка мәсьәләләр.

3. Бер үк вакытта берничә мәсьәлә буенча гавами тыңлаулар үткәрү рөхсәт ителә, әгәр бу һәр мәсьәлә буенча һәр яклап һәм тулы фикер алышуга комачауламаса.

4. Гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача билгеләнмәгән булса, җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслана.

4 статья. Гавами тыңлауларның инициаторлары

Гавами тыңлаулар халык, җирлек Советы (алга таба – Совет), җирлек башлыгы (алга таба – Башлык) инициативасы буенча регламент нигезендә үткәрелә.

Гавами тыңлаулар үткәрү буенча халык инициативасы 18 яшькә җиткән кимендә 10 кеше булган гражданнар төркеменнән чыгарга мөмкин.

## Бүлек 2. ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫН БИЛГЕЛӘҮ

5 статья. Халык тыңлауларын билгеләү

1. Халык яисә Совет инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар Совет карары белән билгеләнә.

Башлык инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар Җирлек башлыгы тарафыннан билгеләнә.

Гавами тыңлаулар Россия Федерациясе законнары белән җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча үткәрелә.

2. Гавами тыңлаулар үткәрү турында халык инициативасын тәкъдим итү һәм инициативага ярдәм итү өчен халык имзаларын җыю өчен 10 кешедән дә ким булмаган инициатив төркем төзелә.

2.1. Инициатив төркем Советка түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

- гавами тыңлаулар мәсьәләсен күрсәтеп, гавами тыңлаулар билгеләү турында гариза һәм 1 нче кушымта нигезендә форма буенча гражданнарның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзаланган аларны үткәрү кирәклеген нигезләү;

- муниципаль хокукый акт проекты (гавами тыңлауларда карауга кертелгән очракта);

- муниципаль хокукый актны кабул итү зарурлыгы нигезләмәсен үз эченә алган максатлары һәм төп нигезләмәләре күрсәтелгән аңлатма язуы (гавами тыңлауларда карауга кертелгән очракта);

- финанс-икътисадый нигезләү (гамәлгә ашыру өстәмә матди һәм башка чыгымнар таләп итә торган муниципаль хокукый актны гавами тыңлауларда карауга керткән очракта);

- 2 нче кушымта нигезендә форма буенча гражданнарның инициатив төркеме исемлеге;

- гражданнарның инициатив төркемен төзү турында карар кабул ителгән җыелыш беркетмәсе;

- инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзаланган, инициатив төркем тарафыннан бирелгән битләр саны, шулай ук муниципаль хокукый акт проекты докладчысы күрсәтелгән документлар исемлеге, (муниципаль хокукый акт проектын гавами тыңлауларда карауга керткән очракта) бергә теркәп җибәрелә торган (сопроводительное) хат.

Гариза һәм беркетмәгә рәислек итүче (гражданнарның инициатив төркеме вәкиле) һәм инициатив төркем җыелышы секретаре тарафыннан имза салынырга тиеш.

2.2. Әлеге статьяның 2.1 пунктчасында билгеләнгән барлык документлар җирлек Советына бер үк вакытта тапшырылса, гариза тапшырылган дип санала.

2.3. Советка гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар кергән көннән алып 30 көн эчендә инициатив төркем тарафыннан гавами тыңлаулар үткәрү инициативасын хуплаучы кешеләрнең имзалары тупланырга һәм тапшырылырга тиеш – әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә форма буенча, Җирлектә яшәүче 18 яшькә җиткән кимендә 30 кешенең имзасы булырга тиеш.

Имзалар советка гавами тыңлаулар үткәрү турында инициативаны тәкъдим итү турында гариза биргән көннән соң килүче көннән җыелырга мөмкин. Имзалар кәгазенә кульязма булмаган ысул белән яки карандаш белән мәгълүмат кертү рөхсәт ителми. Гражданнар турында тиешле белешмәләрдә һәм аларны имзалар кәгазенә кертү даталарында һәм раслау язуында төзәтүләр гражданнар һәм имза җыючылар тарафыннан килештерелергә тиеш.

2.4. Совет эшче төркем төзи һәм имзалар кәгазьләрен биргән көннән алып 10 көн эчендә имзалар кәгазьләрендә бирелгән мәгълүматларны тикшерү үткәрә

Имзаларны һәм имзалар кәгазьләрендәге мәгълүматларны тикшерү нәтиҗәләре буенча имза гамәлдә яки гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин. Әлеге Нигезләмә нигезендә аның гамәлдә түгеллеге билгеләнмәгән булса, имза гамәлдә була.

Түбәндәге очракларда имзалар гамәлдә түгел, ягъни имзалар җыю һәм (яки) имзалар кәгазен рәсмиләштерү тәртибен бозып җыелган имзалар дип танылa:

1) имзалар җыю чорыннан тыш җыелган имзалар;

2) Җирлек муниципаль берәмлегендә яшәүче 18 яше тулмаганнарның имзалары;

3) гражданнарның имзалар кәгазенә үз имзасын үз кулы белән кертү датасын күрсәтмичә куелган имзалары;

4) алар турында белешмәләр имзалар кәгазенә кульязма булмаган ысул белән яки карандаш белән кертелгән имзалар;

5) гражданнар турында тиешле белешмәдә һәм аларны имзалар кәгазенә кертү даталарында төзәтмәләр белән имзалар, әгәр гражданнар һәм имза җыючылар тарафыннан махсус килештерелмәсә.

6) әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта таләпләренә туры килми торган формадагы имзалар кәгазендәге барлык имзалар.

Тикшерү нәтиҗәләре имзалар кәгазьләрен тикшерү беркетмәсе белән рәсмиләштерелә (4 нче кушымта).

2.5. Советның чираттагы утырышында, имза кәгазьләре килгән көннән 15 көн эчендә, түбәндәге очракларда гавами тыңлаулар билгеләү турында яисә гавами тыңлаулар билгеләү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителә:

1) гавами тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәләләр, әлеге Нигезләмәнең 3 статьясында каралган очраклардан тыш, җирле үзидарә органнары компетенциясенә керми;

2) тәкъдим ителгән гамәлдәге имзалар саны халыкның гавами тыңлаулар уздыру турындагы инициативасын алга этәрү өчен җитәрлек түгел;

3) инициативаны тәкъдим итү тәртибе үтәлми;

4) карауга тәкъдим ителә торган муниципаль норматив хокукый акт проекты Россия Федерациясе Конституциясе нигезләмәләренә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, башка норматив хокукый актларга туры килми;

5) шундый ук мәсьәлә чыгарылган гавами тыңлауларны үткәрү датасыннан бер елдан кимрәк вакыт үткән.

2.6. Гавами тыңлаулар билгеләү турындагы гаризаны кире кагу, баш тартуга китергән җитешсезлекләрне бетергән шартта, гавами тыңлаулар билгеләү өчен инициатив төркем тарафыннан документларны кабат кертү өчен киртә түгел.

2.7. Гавами тыңлауларны билгеләү турындагы мәсьәлә Совет Регламенты нигезендә Совет тарафыннан карала.

2.8. Гавами тыңлаулар билгеләү турында гариза кире кагылган очракта, Совет эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта гражданнарның инициатив төркеме вәкаләтле вәкиле адресына язмача дәлилләнгән хәбәрнамә җибәрә.

3. Гавами тыңлауларны билгеләүче Совет, Башлык, тыңлаулар уздыру мәсьәләсе, срогы, вакыты һәм урыны, оештыру комитеты составы, тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль хокукый акт проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе турында тиешле муниципаль актлар кабул итә.

Гавами тыңлауларны үткәрү датасы – гавами тыңлаулар билгеләү турында муниципаль хокукый акт кабул ителгән көннән 30 көн эчендә билгеләнә, әгәр федераль законнарда, Уставта һәм әлеге Нигезләмәдә башкача билгеләнмәгән булса.

6 статья. Гавами тыңлаулар турында мәгълүмат бирү.

1. Авыл җирлегендә яшәүчеләргә гавами тыңлауларның билгеләнүе турында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында, рәсми сайтта һәм (яки) башка мәгълүмати системаларда мәгълүмат стендында бастырып чыгару юлы белән фикер алышына торган муниципаль хокукый актның кушымталы проекты белән (аны карау гавами тыңлауларга кертелгән очракта) гавами тыңлауларны билгеләү турында муниципаль хокукый актны гавами тыңлауларны үткәрү көненә кадәр календарь көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срок эчендә (әгәр федераль законнарда, Уставта, әлеге Нигезләмәдә башкасы каралмаган булса) җиткерелә.

1.1. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре массакүләм мәгълүмат чараларында, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм (яки) башка мәгълүмати системаларда һәм мәгълүмати стендларда басыла.

Мәгълүмати стендлар, мәгълүматтан файдаланучыларны мәгълүмат белән тәэмин итү мөмкинлеген исәпкә алып, яхшы күренә торган урыннарда җиһазландырыла.

Мәгълүмат стендларын урнаштыру эргономика таләпләре нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш, ул мәгълүматтан кулланучының озак вакытлар уңайсыз хәлдә булу ихтыяҗын юкка чыгарырга тиеш.

Мәгълүмати стендларны төсле бизәү эстетик таләпләргә туры килергә тиеш. Мәгълүмати стендлар мәгълүмат битләре урнаштырыла торган А4 форматындагы кесәләр белән җиһазландырылырга мөмкин.

2. Гавами тыңлауларда яки җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект экспозициясен үткәрү мәйданчыгы, шулай ук проект экспозициясенә килүчеләргә консультация бирү вакыты, гавами тыңлаулар яисә җәмәгать фикер алышулары үткәрү турында хәбәр итүгә килештерү буенча кертелә.

Экспозиция эше чорында килүчеләр өчен консультацияләр оештырыла, проект турында басма мәгълүмати материаллар таратыла. Экспозициягә килүчеләр, экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу һәм тәкъдимнәр, искәрмәләр язу өчен тиешле китапка (журналга) фикер алышына торган проектка, мәсьәләгә язма рәвештә үз тәкъдимнәрен, искәрмәләрен кертергә хокуклы.

Проект экспозицияләрендә тәкъдим ителә:

- проект;
- проектка аңлатма язуы;
- документларның Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә алынган килештерү күчермәләре;
- массакүләм мәгълүмат чараларының выходной мәгълүматларын күрсәтеп, проект буенча гавами тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында мәгълүмат хәбәрен бастырып чыгару күчермәсе;
- проектны әзерләүне (эшләүне) оештыручы шундый материалларны биргән очракта, гражданнарга фикер алышына торган проект буенча мәгълүмат бирү максатларында бүтән мәгълүмати һәм демонстрацион материаллар.

## Бүлек 3. ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАРНЫ ӘЗЕРЛӘҮ ҺӘМ ҮТКӘРҮ

### 7 статья. Гавами тыңлауларны әзерләү һәм үткәрү

1. Халык тыңлаулары җирлек халкы өчен уңайлы вакытта үткәрелә (гавами тыңлауларны ял көннәрендә 11.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр яисә эш көннәрендә 17.00 сәгатьтә башлап 20.00 сәгатьтән дә калмыйча тәмамлап үткәрергә тәкъдим ителә).

2. Гавами тыңлаулар билгеләү турында карар кабул иткән җирле үзидарә органы авыл җирлеге Советы депутатлары, авыл җирлеге башкарма комитеты хезмәткәрләре, иҗтимагый оешмалар вәкилләре, гражданнарның инициатив төркеме (әгәр халык тыңлауларын үткәрү инициаторы булып гражданнарның инициатив төркеме чыкса) арасыннан кимендә 5 кешедән торган оештыру комитетын формалаштыра. Оештыру комитеты формалашканнан соң 3 көннән дә соңга калмыйча уздырыла торган беренче утырышта үз составыннан рәисне, рәис урынбасарын һәм секретарен сайлый. Оештыру комитеты утырышта аның әгъзаларының яртысыннан артыгы булганда карар кабул итәргә хокуклы.

Оештыру комитеты тыңлауларда катнашырга теләүчеләргә тыңлаулар үткәрелә торган бинага киртәләрсез керү мөмкинлеген тәэмин итәргә бурычлы.

Гавами тыңлаулар уздырылган көнне оештыру комитеты гавами тыңлауларда катнашучыларны теркәүне оештыра.

3. Гавами тыңлауларда оештыру комитеты рәисе рәислек итә. Рәислек итүче гавами тыңлауларны ача, гавами тыңлауларның мәсьәләсен (мәсьәләләрен), тыңлауларны үткәрү тәртибе буенча тәкъдимнәрне игълан итә, үзен, секретарен һәм экспертларын тәкъдим итә, тыңлауларны үткәрү инициаторларын күрсәтә. Оештыру комитеты секретаре гавами тыңлаулар беркетмәсен алып бара.

4. Рәислек итүче фикер алышу үткәрелә торган мәсьәләне игълан итә һәм гавами тыңлауларны уздыру инициаторлары тарафыннан вәкаләтле затка, экспертларга, шулай ук чыгыш ясарга хокуклы гавами тыңлауларда катнашучыларга сүз бирә. Чыгышларның чираты оештыру комитеты теркәгән гаризалар бирү чираты белән билгеләнә.

5. Тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән экспертлар, үз тәкъдимнәрен кире алырга һәм (яки) гавами тыңлауларда катнашучылар күрсәткән тәкъдимнәргә кушылырга хокуклы.

Фикер алышу нәтиҗәләре буенча, гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кире алынган тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрдән тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләне (мәсьәләләрне) хәл итү буенча бердәм тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр исемлеге төзелә.

6. Тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр белән йомгаклау документын төзегәннән соң, рәислек итүче җирле әһәмияттәге мәсьәләне (мәсьәләләрне) хәл итүнең йомгаклау вариантын катнашучылар тавышына куя. Гавами тыңлаулардагы карарлар ачык тавыш бирү юлы белән теркәлгән тыңлауларда катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тыңлауларда катнашкан һәр кеше бер тавышка ия, ул тавышын җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл иткән өчен бирә, аңа каршы яки тавыш бирүдән тыелып кала. Тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә. Беркетмәгә гавами тыңлауларның рәисе һәм сәркатибе кул куя.

7. Гавами тыңлаулар беркетмәсе нигезендә, гавами тыңлаулар уздырылган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көнлек срокта гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә төзелә (6 нчы кушымта), анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) гавами тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә (сораулар);

2) гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы;

3) гавами тыңлауларны билгеләү турында хокукый актның датасы, номеры һәм атамасы, шулай ук аны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) датасы;

4) гавами тыңлауларны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

5) гавами тыңлауларны үткәрүче оештыру комитеты;

6) гавами тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән чыгыш ясау хокукына ия булучылар турында мәгълүмат;

7) гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кире алынган тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрдән тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләне (мәсьәләләрне) хәл итү буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрнең бердәм исемлеге;

8) җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты;

9) гавами тыңлауларда катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре.

8. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә оештыру комитеты рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана һәм гавами тыңлаулар уздырылган көннән алып, эш көннәрендә исәпләп чыгарыла торган 3 көнлек срокта бастырылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

9. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләләр буенча карар кабул итү өчен җаваплы җирле үзидарә органы тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш. Карау нәтиҗәләре мәҗбүри тәртиптә гавами тыңлаулар инициаторларына, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне караган көннән алып, эш көннәре белән исәпләнә торган 3 көнлек срокта бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән муниципаль берәмлек халкына җиткерелә.

10. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, тәкъдим итү характерына ия.

## Бүлек 4. МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК УСТАВЫ ПРОЕКТЫ, УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА СОВЕТ КАРАРЫ ПРОЕКТЫ, ҖИРЛЕ БЮДЖЕТ ПРОЕКТЫ ҺӘМ АНЫҢ ҮТӘЛЕШЕ ТУРЫНДА ХИСАП, МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКНЕ ҮЗГӘРТЕП КОРУ ТУРЫНДАГЫ МӘСЬӘЛӘ, МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАННАРЫ ПРОЕКТЛАРЫ БУЕНЧА ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАР ОЕШТЫРУ ҺӘМ УЗДЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

8 статья. Җирлек Уставы проектын һәм Уставка үзгәрешләр кертү турында Совет карары

проектын гавами тыңлауларда карау үзенчәлекләре

1. Устав проекты һәм Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Уставта каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, гавами тыңлауларда карала.

2. Устав проекты һәм Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты Совет тарафыннан аны кабул итү турындагы мәсьәләне караганчы 30 көннән дә соңга калмыйча рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Бер үк вакытта күрсәтелгән проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе, гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибе, шулай ук проект буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында Совет карары басыла.

Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук гражданнарның аның фикер алышуында катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) Уставка Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл күрсәтү формасындагы үзгәрешләр кертелгән очракта таләп ителми.

3. Устав проекты яки Советның Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары проекты буенча гавами тыңлаулар Уставта билгеләнгән срокларда үткәрелә, әмма күрсәтелгән проектлар бастырылганнан соң 10 көннән дә иртәрәк түгел .

4. Устав проекты яисә муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру буенча вәкаләтле орган – оештыру комитеты.

9 статья. Җирле бюджет проектын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны гавами тыңлауларда карау үзенчәлекләре

1. Җирле бюджет проекты һәм аның үтәлеше турындагы еллык хисап, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, башка федераль законнарда, Уставта, җирлектә бюджет процессы турындагы нигезләмәдә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, гавами тыңлауларда карала.

2. Җирле бюджет проекты һәм җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап буенча гавами тыңлаулар үткәрүне гамәлгә ашыручы орган – оештыру комитеты.

Җирле бюджет проекты һәм җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында карар кабул итүче орган булып авыл җирлеге Советы тора.

3. Җирле бюджет проекты, җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап буенча гавами тыңлаулар билгеләү турындагы карарлар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә басылып чыгарга тиеш.

4. Җирле бюджет проекты, җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап буенча гавами тыңлаулар җирле бюджет проекты (җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап) басылып чыкканнан соң кимендә 15 календарь көннән соң уздырыла.

10 статья. Муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проектын гавами тыңлауларда карау үзенчәлекләре

Муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проектларына кагылышлы мәсьәләләр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда, «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, гавами тыңлауларга чыгарыла.

11 статья. Муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәләне гавами тыңлауларда карау үзенчәлекләре

1. Муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәлә буенча гавами тыңлаулар,

күрсәтелгән Федераль законның 13 статьясындагы 5 өлешеннән тыш, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясында каралган очракларда үткәрелә.

2. Муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәлә буенча гавами тыңлаулар уздыру буенча вәкаләтле орган – оештыру комитеты.

12 статья. Муниципаль берәмлекләрнең территориаль планлаштыру документлары проектлары буенча мәсьәләләрне җәмәгать фикер алышуларында, гавами тыңлауларда карау үзенчәлекләре

Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияләрне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның иң чик параметрларыннан читләштерүгә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда, җир биләмәләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләләре, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы белән билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып, шулай ук иҗтимагый фикер алышуларга чыгарылырга мөмкин.

Җирлекләрнең генераль планнары проектлары буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын, гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясында китерелгән.

Җирлекләрнең генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар (алга таба – иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар) буенча җәмәгать тыңлаулары яисә гавами тыңлаулар муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә.

Җәмәгать фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда катнашучыларны җәмәгать фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда катнашу өчен тигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатларында җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлаулар үткәргәндә торак пункт территориясе өлешләргә бүленергә мөмкин.

Җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны үткәрү вакыты, муниципаль берәмлек халкына аларны үткәрү турында хәбәр итү мизгеленнән җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырылган көнгә кадәр җирлек уставы һәм (яки) җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан да ким һәм өч айдан артык булмаска тиеш.

Башкарма комитет җитәкчесе, иҗтимагый фикер алышуларның яки гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, карар кабул итә:

1. генераль план проекты белән килешү һәм аны Җирлек Советына җибәрү турында;

2) генераль план проектын кире кагу һәм аны эшләп бетерүгә җибәрү турында.

13 статья. Ачык сервитутлар билгеләү буенча гавами тыңлаулар үткәрү үзенчәлекләре

1. Ачык сервитутлар билгеләү буенча гавами тыңлауларда катнашу хокукына территориясендә ачык сервитут урнаштыру күздә тотылган җирлектә даими яки нигездә яшәүче тыңлаулар үткәрү көненә 18 яшькә җиткән һәр граждан ия.

Гражданнарның гавами тыңлауларда катнашуы ирекле нигездә гамәлгә ашырыла.

Гавами тыңлауларда җирлек территориясендә урнашкан иҗтимагый берләшмәләр, барлык милек рәвешләрендәге коммерцияле булмаган һәм коммерцияле оешмалар катнаша ала.

2. Гавами тыңлаулар 13 статьяның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтле орган яисә физик һәм юридик затлар инициативасы буенча үткәрелә.

Гавами тыңлауларны үткәрү буенча вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

3. Вәкаләтле орган гавами тыңлаулар үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң 7 эш көне эчендә аларны уздыру турында җирлекнең муниципаль актларын бастырып чыгару өчен билгеләнгән рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында белдерү бастыра.

Иҗтимагый тыңлаулар башланыр алдыннан анда катнашучыларны мәҗбүри теркәү үткәрелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

юридик затлар өчен – юриди затның дәүләт теркәве белешмәләренең тулы исеме;

шәхси эшмәкәр өчен – гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм шәхси эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу турындагы мәгълүматлары;

физик зат өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны адресы.

4. Гавами тыңлаулар нәтиҗәсе, аларны үткәрү датасы һәм урыны, катнашучылар һәм тыңлауларда булганнарның саны, гавами тыңлаулар рәисенең, секретаренең фамилиясе, исеме, атасының исеме, чыгышларның эчтәлеге, тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карарлар күрсәтелгән беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Беркетмә ике нөсхәдә төзелә һәм гавами тыңлаулар рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана. Беркетмәгә гавами тыңлауларда катнашучылар исемлеге куела.

5. Аачык сервитут билгеләү турында гавами тыңлауларның нәтиҗәләре вәкаләтле орган тарафыннан карала һәм аның тарафыннан ачык сервитутны билгеләү өчен кирәк булган документларга кушыла.

Ачык сервитутларны билгеләү буенча гавами тыңлаулар беркетмәләрен саклау срогы - өч ел. Ачык сервитутлар билгеләү буенча гавами тыңлаулар беркетмәләрен саклау өчен вәкаләтле орган җитәкчесе җаваплы.

14 статья. Җылылык белән тәэмин итү схемасы проектын гавами тыңлауларда карау үзенчәлекләре

Җылылык белән тәэмин итү схемасы проекты буенча гавами тыңлаулар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 февралендәге 154 номерлы «Җылылык белән тәэмин итү схемаларына, аларны эшләү һәм раслау тәртибенә карата таләпләр турында» карарында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

_______________________________________

муниципаль берәмлек Советы

**ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАР БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА ГАРИЗА**

______ кешесе булган инициатив төркем, исемлек кушымта итеп бирелә, муниципаль берәмлек халкы инициативасы буенча _______________________________________ мәсьәлә буенча гавами тыңлаулар билгеләргә тәкъдим итә:

_______________________________________

Гавами тыңлаулар үткәрү кирәклеген нигезләү:

_______________________________________

_______________________________________

_______________________________________

Кушымта (фактта бирелә торган документлар күрсәтелә):

1) муниципаль хокукый акт проекты (кертелгән очракта);

2) аңлатма язуы;

3) финанс-икътисадый нигезләү (гамәлгә ашыру өстәмә матди һәм башка чыгымнар таләп итә торган муниципаль хокукый акт кертелгән очракта);

4) гражданнарның инициатив төркеме исемлеге;

5) гражданнарның инициатив төркемен төзү турында карар кабул ителгән җыелыш беркетмәсе;

6) сопроводительный хат.

Гражданнарның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле _______________ _______________
(имза) (Ф.И.О.)

Гражданнарның инициатив төркеме секретаре _______________ _______________
(имза) (Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә 2 нче кушымта

______________________________
муниципаль берәмлек Советы

**ИНИЦИАТИВ ТӨРКЕМ ӘГЪЗАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ**

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм туган елы (18 яшьтә – туу көне һәм ае) | Яшәү урыны адресы | Паспорт мәгълүматлары, шәхесне раслаучы документ сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән | Шәхси имза |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Гражданнарның инициатив төркеме вәкаләтле вәкиле ________________ ________________
(имза) (Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

**ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫНЫҢ ИМЗАЛАР КӘГАЗЕ**

Сорау буенча:

«_____________________________________________________________

_____________________________________________________________»

Без, түбәндәгеләр, ________________________ муниципаль берәмлек халкы инициативасы буенча гавами тыңлаулар үткәрүне хуплыйбыз, сорау буенча:

«_____________________________________________________________

_____________________________________________________________

_____________________________________________________________»

| № т/б | Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | 18 яшьтә – туган елы (өстәмә: туган числосы һәм ае) | Яшәү урыны адресы | паспорт яисә гражданинның паспортын алмаштыра торган документ номеры, сериясе | Шәхси имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |

Имзалар кәгазен раслыйм:

_____________________________________________________________

_____________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, гражданның паспорты яки паспортын алмаштыручы документның сериясе, номеры һәм бирү датасы, аны биргән органның исеме яки коды, имзалар җыйган затның яшәү урыны адресы, аның имзасы һәм аны кертү датасы)

Гражданнарның инициатив төркеме вәкаләтле вәкиле

_______________ _______________

(имза) (Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 4 нче кушымта

## ХАЛЫК ТЫҢЛАУЛАРЫНЫҢ ИМЗАЛАР КӘГАЗЕН ТИКШЕРҮ БЕРКЕТМӘСЕ

Сорау буенча: ________________________________________________

«________________________________________________».

________________________________________________

Муниципаль берәмлек советына тәкъдим ителгән гражданнар имзалары саны __________________, халык тыңлауларын үткәрү инициативасын хуплаучы гражданнар имзалары________________________________________________.

___________ сайлаучыларның имзалары тикшерелде, алар арасыннан:

яраксыз дип табылды________________ түбәндәге сәбәпләр буенча:

________________________________________________;

________________________________________________

Яраксыз имзалар саны – ______________________________.

Советка фактта тәкъдим ителгән имзаларның гомуми саны ______________ тәшкил итә.

Эшче төркем җитәкчесе ________________ ________________
(имза) (Ф.И.О.)

Эшче төркем әгъзалары ________________ ________________
(имза) (Ф.И.О.)

________________ ________________
(имза) (Ф.И.О.)

_________________________
(дата, вакыты)

Гражданнарның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле ________________ ________________
(имза) (Ф.И.О.)

Гражданнарның инициатив төркеме секретаре ________________ ________________
(имза) (Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә 5 нче кушымта

## ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАР БЕРКЕТМӘСЕ

«____» _________ 20_____ ел №_____

___________

Гавами тыңлаулар ________________________________________________
инициативасы буенча ________________________________________ билгеләнгән
______________________________ № _____
(муниципаль хокукый акт)
________________________________________________________________
(муниципаль хокукый актның исеме)
басылган (халыкка җиткерелгән): ______________________________________
үткәрелгән ______________________________________________________
адрес буенча: ____________________________________________________
________________________________________________________________
(үткәрү датасы)

Оештыру комитеты:________________________________________________
Катнаштылар: ____________________________________________________
Рәислек итүче: __________________________________________________
Секретарь: ______________________________________________________
Экспертлар: _____________________________________________________
Гавами тыңлауларда катнашучылар: (теркәлгән катнашучылар саны)
________________________________________________________________
Гавами тыңлауларда чыгыш ясаучылар:
________________________________________________________________
(Ф.И.О.)

Тыңланды:
1. _____________________________________________________________
(Ф.И.О.)
2. _____________________________________________________________
(Ф.И.О.)
3. _____________________________________________________________
(Ф.И.О.)

Телдән һәм язма рәвештә кертелгән рекомендация һәм тәкъдимнәр саны________________________, шул исәптән:

| № т/б | Рекомендация һәм тәкъдимнәр | Гариза бирүче |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Гавами тыңлауларның рәисе____________ ______________________
(имза) (Ф.И.О)

Гавами тыңлауларның секретаре______________________________________
(имза) (Ф.И.О)

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә 6 нчы кушымта

## ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАР НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘ

«___» _________ 20______ ел                                        № ___________

Гавами тыңлаулар ___________________________________________ инициативасы буенча ________________________________________________________ билгеләнгән

(муниципаль хокукый акт)

_____№ _____ ___________________________________________________

(муниципаль хокукый актның исеме)

басылган (халыкка җиткерелгән):________________________________ үткәрелгән адрес буенча: _______________________________ ______________________

(үткәрү датасы)

Гавами тыңлауларга чыгарыла торган сорау (сораулар) _________________________

Гавами тыңлауларны үткәрү инициаторы ___________________________________

4) гавами тыңлауларны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

Гавами тыңлаулар үткәргән оештыру комитеты ______________________________

Гавами тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән чыгыш ясау хокукына ия булучылар турында мәгълүмат ________________________________________________

Гавами тыңлауларга чыгарылган җирле әһәмияттәге мәсьәләне (мәсьәләләрне) хәл итү буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрнең бердәм исемлеге:

| Фикер алышуга чыгарылган сораулар | | Экспертлар һәм катнашучыларның рекомендацияләре һәм тәкъдимнәре | | Тәкъдимнәр рекомендацияләр) кертелде хупланды) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| № т/б | сорауның формулировкасы яки проектның исеме | № т/б | тексты тәкъдим | Экспертның Ф. И. О. катнашучы) | |
| 1 | | 1.1. | | | |
| | | 1.2 | | | |
| 2 | | 2.1 | | | |
| 3 | | 2.2<br>3.1<br>3.2 | | | |

Җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты: ______________________

Гавами тыңлауларда катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре:

риза _____________________ (кеше)

каршы_________________ (кеше)

битараф___________ (кеше)

Оештыру комитеты рәисе _________________________

Оештыру комитеты секретаре _________________________